ГЛАВА
Новобизякинского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2020 № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Аул авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Аул торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 24 ноябрендә 09 сәг 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Аул торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Варклед-Аулда урам яктыртуын карап тоту, урам яктырткычларын алыштыру чараларын сатып алу, урнаштыру

2. Юлларга хезмәт күрсәтү, кар чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу) «РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Варклед-Аул ав., Колхоз ур., 1 нче йорт янындагы мәйданчыкта үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.С.Салихов

Совет Новобизякинского сельского поселения
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002477